| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 29

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мәэмин-Каратай авылы Механизаторлар урам һәм Нагорная урамы буенча юллардагы чокырларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы З.Р.Шәрәпова

ИНН 1625001112
КПП 164901001